ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 18 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 8 (II өлеш), № 12 (Х өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2012, № 1, № 9; 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның дүртенче абзацында «торак урынына» сүзләрен «торак урыннарына» сүзләренә алмаштырырга;

2) 6 статьяда:

а) исемдә «торак урынына» сүзләрен «торак урыннарына» сүзләренә алмаштырырга;

б) 1 өлешнең «ж» пунктчасында «дәүләт теркәве органнары» сүзләрен «дәүләт кадастр исәбенә алуны, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны, Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрын алып баруны һәм Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирүне гамәлгә ашыручы орган (алга таба – хокукларны теркәү органы)» сүзләренә алмаштырырга;

в) 2 өлешнең «а» пунктчасында «мөлкәти хокукларны дәүләт исәбенә алу һәм теркәү органнарыннан» сүзләрен «хокукларны теркәү органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлештә «Торак урынына» сүзләрен «Торак урыннарына» сүзләренә алмаштырырга;

д) 6 өлештә «гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керемнең» сүзләрен «һәр гаилә әгъзасына туры килә торган керемнең» сүзләренә алмаштырырга;

3) 7 статьяның 2 өлешендә «дәүләт хакимияте органнарына, салым һәм таможня органнарына, бүтән» сүзләрен «дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм» сүзләренә алмаштырырга;

4) 10 статьяда:

а) «д» пунктчасында:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында укучыларга, фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге уку рәвешендә белем алучы аспирантларга һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына, дини белем бирү оешмаларында укучыларга түләнә торган стипендияләр, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә медицинага бәйле сәбәпләр буенча академик ялда булу чорында түләнә торган компенсация түләүләре;»;

бишенче абзацта «һөнәри әзерләнү, яңа һөнәргә өйрәнү һәм квалификация күтәрү» сүзләрен «һөнәргә өйрәнү һәм өстәмә һөнәри белем алу» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «ж» пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм хокук саклау эшчәнлеге белән бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка органнар хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук Россия Федерациясе законнарында каралган даими бирелә торган өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү;»;

өченче абзацта «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының» сүзләрен төшереп калдырырга, «хокук саклау хезмәтенең башка органнарыннан» сүзләрен «, хокук саклау эшчәнлеге белән бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу Россия Федерациясе законнарында каралган башка органнардан» сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 1 өлешендә «күчемсез мөлкәтне кадастр исәбенә алуны һәм аның дәүләт кадастрын алып баруны гамәлгә ашыра торган органнан» сүзләрен «хокукларны теркәү органыннан» сүзләренә алмаштырырга;

6) 23 статьяда:

а) 1 өлешнең өченче абзацында «дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы» сүзләрен «дәүләт органының, җирле үзидарә органының,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлештә «Торак урыннарына мохтаҗлар буларак» сүзләрен «Торак урынга мохтаҗ буларак» сүзләренә алмаштырырга;

7) 25 статьяның 1 өлешендәге алтынчы абзацында «җир кишәрлеге» сүзләреннән соң «(бакча өчен җир кишәрлегеннән тыш)» сүзләрен өстәргә;

8) кушымтада:

а) 2 пунктның «а» пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1 – (1 + ПС)$^{-КП}$) / (0,3 х РС), монда»;

б) 4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ПЛТ = ПЖ х ПС / (1 – (1 + ПС)$^{-КП}$), монда».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 7 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 7 пункты 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2018 ел, 07 ноябрь
№ 85-ТРЗ